КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 март г.Казань № 238

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасының «Халыкны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру һәм хезмәт миграциясен җайга салу. Эшкә урнашканда яшь инвалидларга даими булышлык күрсәтеп тору» ярдәмче программасына 2 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 17 февраль, 92 нче; 2014 ел, 31 май, 371 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 643 нче; 2014 ел, 1 декабрь, 936 нчы; 2015 ел, 26 март, 186 нчы; 2015 ел, 28 август, 626 нчы; 2015 ел, 25 сентябрь, 710 нчы; 2015 ел, 29 декабрь, 1000 нче; 2016 ел, 24 март, 160 нчы; 2016 ел, 13 август, 554 нче; 2016 ел, 6 декабрь, 898 нче; 2017 ел, 13 март, 134 нче; 2017 ел, 13 июль, 479 нчы; 2017 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2017 ел, 7 декабрь, 943 нче; 2018 ел, 24 гыйнвар, 35 нче;

2018 ел, 26 февраль, 107 нче; 2018 ел, 12 апрель, 235 нче; 2018 ел, 3 июль, 540 нчы; 2018 ел, 13 сентябрь, 775 нче; 2018 ел, 23 ноябрь, 1042 нче; 2019 ел, 26 гыйнвар, 43 нче; 2019 ел, 4 февраль, 66 нчы; 2019 ел, 28 февраль, 141 нче; 2019 ел, 30 апрель, 366 нчы; 2019 ел, 11 сентябрь, 816 нчы; 2019 ел, 10 декабрь, 1132 нче; 2020 ел, 7 февраль, 80 нче; 2020 ел, 25 май, 421 нче; 2020 ел, 24 июль, 621 нче; 2020 ел, 26 октябрь, 956 нчы; 2020 ел, 30 декабрь, 1229 нчы; 2021 ел, 21 май, 353 нче; 2021 ел, 19 июль, 586 нчы; 2021 ел, 6 ноябрь, 1055 нче; 2022 ел, 27 гыйнвар, 62 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасының «Халыкны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру һәм хезмәт миграциясен җайга салу. Эшкә урнашканда яшь инвалидларга даими булышлык күрсәтеп тору» ярдәмче программасына 2 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Халыкны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру һәм хезмәт миграциясен җайга салу. Эшкә урнашканда яшь инвалидларга даими булышлык күрсәтеп тору» ярдәмче программасы максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм 2019 – 2025 елларга 2 нче ярдәмче программа чаралары буенча финанслау» таблицасында:

1.1 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ТР Хезмәт министрлыгы[1], ХЭТИ ДУ»;

4.1 пунктның 4.1.6 пунктчасында:

1 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.6. Инвестиция проектлары нигезендә эшчәнлекне реструктуризацияләүне һәм модернизацияләүне гамәлгә ашыручы оешмаларның хезмәткәрләрен, шулай ук эштән азат итү куркынычы астындагы хүезмәткәрләрне алдан һөнәри укытуны һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру»;

4 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«алдан һөнәри укытуга һәм өстәмә һөнәри белем бирүгә юнәлдерелгән инвестиция проектлары нигезендә эшчәнлекне реструктуризацияләүне һәм модернизацияләүне гамәлгә ашыручы оешмалар хезмәткәрләре, шулай ук эштән азат итү куркынычы астындагы хезмәткәрләрнең тармак министрлыклары заявкалары нигезендә алдан һөнәри укытуга мохтаҗ әлеге хезмәткәрләрнең гомуми санындагы өлеше, процент»;

5.1 пунктның 1 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Эшсезлек буенча пособиеләрне үз вакытында түләү һәм эшсезлек буенча пособиеләрне түләү чоры беткәннән соң матди ярдәм күрсәтү юлы белән эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүне тәэмин итү».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин